*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2024-2025 нче уку елы)
**5 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 90 минут**
**Максималь балл – 45**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Саңгырау тартык авазны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) [г]
   ә) [с]
   б) [м]
   в) [ж]

2. Нечкә сузык авазлардан гына торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тукран
   ә) куян
   б) китап
   в) идән

3. Сүз басымы дөрес куелмаган рәтне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) барма′гыз
   ә) ни′чек
   б) кайда′
   в) укучыларны′

4. *Тар* сүзенең антонимын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тигез
   ә) туры
   б) кыска
   в) киң

5. Парлы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) җиләк-җимеш
   ә) ташбака
   б) белем
   в) РФ

6. Төшем килешендәге исемне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) урманның
   ә) урманга

б) урманны
в) урманда

7. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
а) яшел
ә) яшелрәк
б) ямь-яшел
в) яшькелт

8. Боеру җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**
а) Бүген без инша язабыз.
ә) Син кичә китап укыдыңмы?
б) Урамда көчле яңгыр ява.
в) Тәнәфестә сыйныф бүлмәсен җилләтегез.

## II. Теоретик бирем.

Төшеп калган сүзләрне языгыз. **(5 балл)**

[д] – __________ тартык аваз. [ә] – нечкә ____________ аваз. Мәгънәләре охшаш булган сүзләр _________ дип атала. Татар телендә ___________ килеш бар. *Укый* – _______________ заман хикәя фигыль.

## III. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**
*Сколько месяцев в году? Ученики с большим интересом читают рассказы о природе. Дети пошли в лес за ягодами и грибами.*

2. Мәкальне укыгыз, биремнәрне башкарыгыз.
*Алтын җирдән табыла, белем – китаптан.* (Мәкаль)
2.1. Нечкә сузык авазлардан гына торган сүзләрне языгыз. **(1 балл)**
2.2. *Алтын* сүзен килешләр белән төрләндереп языгыз. **(2 балл)**
2.3. Фигыльнең заманын, зат-сан белән төрләнешен языгыз. **(3 балл)**

3. Сез мәкальне ничек аңлыйсыз? Шул хакта 6 җөмлә языгыз. **(12 балл)**